КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 апрель г.Казань № 299

2018 елда урманнарны янгыннардан
саклау чаралары турында

Россия Федерациясе Урман кодексының 52 – $53^{8}$, 83, 96 һәм 97 статьялары, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы һәм «Янгын куркынычсызлыгы хакында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 30 июнь, 417 нче карары нигезендә һәм урман фонды җирләрендә, шулай ук урман кишәрлекләрендә һәм җирләрне тискәре табигый, антропоген һәм техноген күренешләрдән саклауны тәэмин итү өчен күздә тотылган, Татарстан Республикасы милкендәге урман үсентеләре биләгән җирләрдә урманнардагы янгыннарны сүндерү вәкаләтләрен башкару, урманнардагы янгыннарны сүндергәндә кызыксынучы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек итү дәрәҗәсен күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елда Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгыннардан саклау эшен оештыру чаралары планын (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм муниципаль районнар башкарма комитетлары белән берлектә урманнарда янгыннар чыгуны профилактикалауга һәм аларга каршы көрәшүгә юнәлдерелгән оештыру-техник чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итәргә;

башкарыла торган эшләрнең, шулай ук урманнардагы янгыннарны сүндерү буенча күрсәтелгән хезмәтләрнең күләмнәре дөрес булу-булмауны һәм аларның сыйфатын, янгыннарга каршы чаралар үткәрүне һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосындагы учреждениеләрнең янгын сүндерү-

химия станцияләрен янгыннар чыгу куркынычы булган сезонга әзерләүне гамәлгә ашыруны тикшерүдә тотарга;

урман массивларында урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгын сүндерү техникасы белән су алу өчен мәйданчыклар оештырырга, шулай ук аларга транспорт тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген тәэмин итәргә;

расланган һәм прокуратура органнары белән килештерелгән тикшерүләр планы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосындагы учреждениеләр, шулай ук урман фонды җирләрендә эшләр башкаручы оешмалар һәм урман кишәрлекләрен арендага алучылар көчләренең һәм чараларының урманнардагы янгыннарны сүндерүгә әзерлеген ачыклау буенча тикшерүләр оештырырга һәм гамәлгә ашырырга;

бүлеп бирелгән бюджет акчасы исәбеннән махсуслаштырылган оешма тарафыннан авиация ярдәмендә урманнарны саклауны тәэмин итәргә;

урманнардагы янгыннарны алар башланып киткән стадиядә үз вакытында ачыклау, чикләү һәм бетерү буенча оператив чаралар күрүне тәэмин итәргә;

урманнарны янгыннардан саклау функцияләрен үтәү өчен кызыксынучы оешмаларны (шул исәптән махсуслаштырылган авиация оешмаларын) һава торышының тәүлеклек, айлык һәм периодик фаразлары, урман фонды җирләрендә янгын чыгу куркынычы фаразлары, һава торышы турындагы көнлек сводкалар, спутник метеорология мәгълүматы белән тәэмин итәргә;

урман фонды җирләрендә чыккан урман янгыннарын сүндерүне – федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына, ә Татарстан Республикасы милкендәге урман кишәрлекләрендә һәм урман үсентеләре биләгән җирләрдә һәм урман кишәрлекләрендә чыкканнарын урманнардагы янгыннарны сүндерү планнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына оештырырга;

урманнардагы янгыннарны сүндерүгә коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләрен, аларның янгынга каршы техникасын һәм транспорт чараларын, шулай ук гражданнарны җәлеп итәргә;

урман фонды җирләрендә, шулай ук башка категорияләрдәге җирләрдә һәм урман кишәрлекләрендә чыккан урман янгыннарының исәбен алып барырга;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы арасындагы урманнарда янгыннар чыгуны кисәтү һәм аларны сүндерү өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә янгыннар чыгу куркынычы зур булган чор башыннан алып көн саен Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә урманнардагы янгыннар турында мәгълүматлар кертергә;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы белән чиктәш Россия Федерациясе субъектларының урман

мөнәсәбәтләре өлкәсендәге башкарма хакимият органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешүләр нигезендә чик буендагы территорияләрдә урманнарда янгыннар чыгу, аларны чикләү һәм бетерү турында мәгълүмат алмашуны тәэмин итәргә;

урманнардагы янгыннарны сүндерүгә федераль бюджеттан субвенцияләр алу өчен документларны үз вакытында әзерләүне, рәсмиләштерүне һәм кертүне тәэмин итәргә;

урманнардагы янгыннарны федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына сүндерүгә чыгымнар формалаштыру һәм аларның исәбен алып бару тәртибе буенча Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы тәкъдимнамәләре нигезендә бу максатлар өчен җәлеп ителә торган оешмалар белән үз вакытында исәп-хисаплар ясарга;

зыянның күләмен билгеләү, урманнарда янгын чыгуда гаепле затларны ачыклау һәм аларны законнар белән билгеләнгән җаваплылыкка тарту, шулай ук янгын чыгу аркасында салынган зыянны каплау буенча кирәкле чараларны үз вакытында үткәрүне оештырырга.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына урманнарда янгыннар чыгуда гаепле затларны ачыклауда законнарда билгеләнгән тәртиптә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына түбәндәгеләрне башкарырга, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тәкъдим итәргә:

язгы-җәйге чорда янгыннар санын киметүгә юнәлдерелгән янгын-профилактика чаралары комплексын эшләргә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне, янгыннар буенча оператив хәлне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны, шулай ук язгы-җәйге чорда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга;

янгын сүндерү терәк пунктларының куелган бурычларны үтәүгә әзерлеген, шулай ук аларны янгын-техник кораллар һәм җиһазлар, янгын сүндерүче матдәләр һәм ягу-майлау материаллары белән максималь комплектлауны тәэмин итәргә;

гражданнар җыеннары үткәрүдә һәм янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалауга катнашырга;

барлыкка килгән шартларны исәпкә алып, кирәк булганда көчләрнең һәм чараларның (шул исәптән объектларны саклау буенча) урынын алыштырырга;

резервтагы янгын сүндерү техникасын хәрби исәпкә кую буенча чаралар күрергә;

төп янгын сүндерү автомобильләрен (хәрби исәп һәм резерв) коры үлән һәм япма янып китүен сүндерү өчен кораклар (шапылдаткычлар) белән комплектлап бетерергә.

5. Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына милекнең барлык төрләрендәге авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр белән берлектә:

урман һәм торф массивларына тоташкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә язгы кыр һәм урып-җыю эшләрен үткәргәндә урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләрен үтәүне һәм Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә коры үләннәрне һәм ашлык суктырганнан соң калган калдыкларны, шулай ук агач-куак үсемлекләрен яндыруга юл куймау чараларын күрергә;

басуларның урман һәм торф массивларына, дала полосасына, автомобиль юлларына һәм тимер юлларга тоташкан урыннарын киңлеге кимендә 4 метр булган полоса итеп сөрү буенча чаралар күрергә;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнеке булган урман һәм торф массивларына тоташкан территорияләрне чүп-чардан һәм корыган агач-куаклардан чистартып карап тотарга;

гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракларда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең күчмә янгын сүндерү техникасы белән ирекле янгын сүндерү формированиеләренең тәүлек әйләнәсе кизү торуын оештырырга;

ясалма сулыкларга һәм су этәрү каланчаларыннан янгын сүндерү техникасы су алу өчен җайланмаларга керү урыннарын эш хәлендә тотарга.

6. Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары буендагы юл кырыйларын, откосларны һәм бүлеп бирелгән полосаларны чүп-чардан, кирәкмәгән үлән һәм агач-куак үсемлекләрдән системалы рәвештә чистартып торуны тәэмин итәргә.

7. «Волго-Вятскуправтодор» федераль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

урман массивлары аша үтә торган федераль әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын, төзекләндерү элементларын янгыннардан саклау буенча кирәкле чаралар күрүне;

федераль әһәмияттәге автомобиль юллары буендагы юл кырыйларын, откосларны һәм бүлеп бирелгән полосаларны чүп-чардан, кирәкмәгән үлән һәм агач-куак үсемлекләрдән системалы рәвештә чистартып торуны тәэмин итүне.

8. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

мобилизацияләнгән хәрби хезмәткәрләрне (100 кешегә кадәр) урнаштыру һәм тукландыру, шулай ук аларны кирәкле инструмент һәм урманнарда янгын чыккан

урынга илтеп җиткерү өчен транспорт чаралары белән тәэмин итү мөмкинлеген күздә тотуны;

профилактика төркемнәре тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан һәм урман фонды җирләренә турыдан-туры тоташкан торак пунктларга тикшерүләр оештыруны;

табигый янгыннар чыгу куркынычы янаганда һәм чыкканда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы звеноларына караган көндәлек идарә итү органнары эшчәнлеген яраштыруны гамәлгә ашыруны;

урман янгыннары ялкыны торак пунктларга һәм гражданнарның җәйге ялы объектларына күчкән очракларда халыкны эвакуацияләүне тәэмин итүне, бу вакытта техниканың кирәкле санын, эвакуация урыннарын, эвакуацияләнгәннәрнең туклануын һәм медицина ярдәме күрсәтү белән тәэмин ителүен алдан ук күздә тотуны;

урман фондында урнашкан һәм урман фонды җирләренә турыдан-туры тоташкан торак пунктларны һәм икътисад объектларын саклау өчен минералланган полосалар булдыру эшен оештыруны;

урман фонды җирләрендә урнашкан һәм урман фонды җирләренә турыдан-туры тоташкан торак пунктларны һәм объектларны янгынга каршы тору өчен су белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар күрүне;

урман фонды җирләрендә урнашкан һәм урман фонды җирләренә турыдан-туры тоташкан торак пунктларда, дача кооперативларында һәм бакчачылык җәмгыятьләрендә төннәрен патрульлек итү оештыруны;

урман янгыннарына каршы көрәшү һәм урман янгыннарын (торф януны) сүндерүгә халыкны, эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне, шулай ук бу оешмаларның янгынга каршы техникасын һәм транспорт чараларын җәлеп итү чараларын үткәргәндә оешмаларның гамәлләрен яраштыруны тәэмин итү чараларын күрүне;

урман янгыннарына каршы көрәшкә җәлеп ителә торган затларны күчеп йөрү чаралары, туклану һәм медицина ярдәме белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне;

урман фонды җирләрендә урнашкан торак пунктларны телефон элемтәсе, янгынга каршы су белән тәэмин итү, табигый һәм ясалма сулыкларда пирслар ясау, су этәрү каланчаларын янгын сүндерү автомобильләре өчен су алу җайланмалары белән җиһазландыру, урман массивларына тоташкан торак пунктлар һәм икътисад объектлары чикләре буйлап минералланган полосалар үткәрү чараларын күрүне;

шәһәр һәм авыл торак пунктлары җирләрендә урнашкан урман үсентеләрен янгыннардан саклауны яхшырту чараларын күрүне:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы көчләре һәм чараларының урман янгыннар белән бәйле гадәттән тыш хәлләргә әзерлеген тикшерү буенча укулары һәм тренировкалар үткәрүне;

2018 елгы янгын куркынычы сезонында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында муниципаль хокукый актлар кабул итүне;

янгын куркынычы сезонына әзерлек чаралары планын раслауны;

саклык характерындагы гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү чараларын үткәрүгә финанс чаралары резервын булдыруны;

янгынга каршы су белән тәэмин итүнең ясалма чыганакларының көн саен мониторингын тәэмин итүне;

составларына социаль хезмәтләр, попечительлек советлары, полиция, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, торак-коммуналь оешмалар хезмәткәрләрен һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен кертеп, профилактика төркемнәре төзүне;

чүп-чар, коры үлән ягуны кисәтү максатында профилактика төркемнәре тарафыннан торак пунктларны карап тикшерүләр оештыруны;

янгын сүндерү техникасы белән ирекле һәм муниципаль янгыннан саклау формированиеләре әгъзаларының тәүлек әйләнәсе кизү торуын оештыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны;

янгыннарны сүндерү өчен янгын сүндерүгә яраклаштырылган су сибү һәм башка техниканы җәлеп итүне оештыруны;

тора пунктларны һәм муниципаль милектәге объектларны янгынга каршы су белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар күрүне;

эре урман һәм торф янгыннарын юк иткәндә файдалану өчен полиэтилен торбаларны оператив алып килү мөмкинлеген күздә тотуны.

9. Урманга терәлеп тора торган территориягә ия булган, файдаланган һәм (яки) идарә иткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, учреждениеләргә, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, шәхси эшмәкәрләргә, вазыйфаи затларга, Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына, гражданлыгы булмаган затларга кар эрегән көннән алып тотрыклы яңгырлы көзге һава торышы яки кар катламы барлыкка килгәнгә кадәр урманнан кимендә 10 метр киңлектә полосаны коры үлән үсемлекләреннән, калдыклардан, чыбык-чабактан, киселгән калдыклардан, чүп-чардан һәм башка яна торган материаллардан чистартуны тәэмин итәргә яисә урманны кимендә 0,5 метр киңлектә янгынга каршы минерал полоса яки бүтән янгынга каршы киртә белән бүлеп алырга тәкъдим итәргә.

10. Үз ведомстволары буйсынуындагы оешмалары балансында урман фонды җирләрендә һәм урман фонды җирләренә тоташкан җирләрдә урнашкан объектлары (шул исәптән балаларны савыктыру лагерьлары) булган Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләренә янгынга каршы кисәтү, профилактика чаралары комплексын үткәрүне һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

11. Төрле милек рәвешендәге оешмалар җитәкчеләренә урман янгыннарын сүндерү планнары (оператив (мобилизация) планнар) нигезендә урман янгыннарын сүндерү өчен көчләр һәм чаралар бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

12. «Түбән Кама» илкүләм паркы», «Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы» федераль дәүләт учреждениеләре, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Урман хуҗалыгы идарәсе» федераль дәүләт автоном учреждениесенең Марий филиалы, Горький тимер юлының «Россия Федерациясе тимер юл транспортының ведомство сагы» федераль дәүләт предприятиесе

филиалының структур бүлекчәсе – Казан ведомство сагы отряды җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

югарыда күрсәтелгән учреждениеләргә беркетелгән территорияләрдә янгынга каршы профилактика чаралары комплексын үз вакытында үтәүне тәэмин итүне;

үз ведомстволары буйсынуындагы учреждениеләр чикләрендә кинәт янгын чыгу һәм кабынып китү очраклары турында Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына оператив мәгълүмат кертүне.

13. «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә янгынга каршы профилактика чаралары комплексын үз вакытында үтәүне, шул исәптән линия объектларының (электр тапшыру линияләренең) саклау зоналарында урман янында чүпләнүдән һәм чүп-чардан чистартуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2006-2008 елларда урманнарны янгыннан һәм корткычлардан, авырулардан саклау чаралары турында» 2006 ел, 31 август, 440 нчы;

«2010 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2010 ел, 5 апрель, 236 нчы;

«2011 елда Татарстан Республикасы урманнарын, торак пунктларын һәм башка территорияләрен янгыннардан саклау чаралары турында» 2011 ел, 25 апрель, 331 нче;

«2012 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2012 ел, 29 март, 248 нче;

«2013 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2013 ел, 25 апрель, 281 нче;

«2014 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2014 ел, 31 март, 202 нче;

«2015 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2015 ел, 28 март, 194 нче;

«2016 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2016 ел, 15 апрель, 231 нче;

«2017 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2017 ел, 31 май, 328 нче.

15. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 27 апрель, 299 нче
карары белән расланды

**2017 елда Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгыннардан саклау эшен оештыру чаралары планы**

| Т/с | Чара исеме | Чараны үтәү вакыты | Үтәүче |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Янгын сүндерү-химия станцияләренең янгыннар чыгу куркынычы булган сезонга әзерлеген тәэмин итү чаралары комплексын үтәү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 2. | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы белән күздә тотылган урманнарны янгыннардан саклау чараларын тормышка ашыру | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 3. | Министрлыклар, ведомстволар, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләре һәм шактый зур мәйданнарда урманнардан файдаланучы арендаторлар катнашында урманнарны янгыннардан саклау мәсьәләсе буенча видеоконференция рәвешендә киңәшмә үткәрү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 4. | Урман фонды җирләрендә (җир өсте һәм авиация зоналарында) патрульлек итү маршрутларын эшләү һәм графикларын раслау | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5. | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган Янгынга каршы дәүләт хезмәте белән урман янгыннарын сүндерүгә әзерләнү максатларында үзара хезмәттәшлек итүгә өйрәнү буенча практик дәресләр һәм күнегүләр үткәрү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 6. | Урман янгыннарын сүндерү җитәкчеләрен, янгын сүндерү-химия станцияләре хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт бюджет учреждениеләре белгечләрен укытуны оештыру һәм үткәрү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 7. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасының Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләр һәм Татарстан Республикасының Дәүләт янгынга каршы хезмәте белән көчләренең һәм чараларының үзара хезмәттәшлегенә ирешү буенча өйрәнүләр үткәрү | май | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, урманчылылар |
| 8. | Урман массивларына тоташкан территорияләрдә гражданнарның күпләп ял итү урыннарында патрульлек итү оештыру | май – сентябрь | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 9. | Янгыннар чыгу куркынычы югары булган вакыт җиткәндә халыкның урманнарга керүен чикләү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыкларын үз вакытында әзерләүне тәэмин итү | янгын куркынычы сезоны дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 10. | Урман янгыннары турындагы космос мониторингы мәгълүматын кабул итүне һәм анализлауны тәэмин итү | янгын куркынычы сезоны дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 11. | Урман массивларында яки аларга якын урнашкан торак пунктлар янында, шул исәптән Татарстан Республикасының, Марий Эл Республикасы һәм Удмуртия Республикасы белән чикләрендә, минералланган полосаларның булганнарын яңарту һәм яңаларын булдыру | апрель – май | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, муници паль берәмлекләрнең башкарма хакимият органнары (килешү буенча) |
| 12. | Махсуслаштырылган диспетчерлык хезмәтенең тәүлек дәвамында эшләвен тәэмин итү | янгын куркынычы сезоны дәвамында | «Урман янгын үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 13. | Янгынга каршы кисәтү, профилактика чаралары комплексын үткәрүне тәэмин итү һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тикшерүдә тоту | янгын куркынычы сезоны дәвамында | Ведомстволарындагы оешмалар балансларында урман фонды территорияләрендә һәм урман фондына чиктәш җирләрдә урнашкан объектлары, шул исәптән балаларны сәламәт-ләндерү лагерьлары булган Татарстан Республикасы башкар-ма хакимият органнары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 14. | Кешеләр аеруча еш була торган урыннарда (беренче чиратта, торак пунктлардан транспорт чыга торган автомобиль һәм тимер юллары буенда) янгынга каршы тематика буенча билбордлар һәм баннерлар сериясен урнаштыруны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урманчылык» дәүләт казна учреждениеләре |
| 15. | Урманнарның һәм торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне, янгыннар буенча оператив хәлне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны, шулай ук халыкка көндәлек тормышта янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат бирүне оештыру, Халыкка мәгълүмат бирү һәм хәбәр итү буенча гомумроссия комплекслы системасы системаларын куллануны кертеп | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 16. | Үткән елларда урманнардагы янгыннар, җил аудару һәм кар сындыру аркасында салынган зыяннарны бетерү эше һәм урманның күрсәтелгән кишәрлекләрендә янгын буенча хәлне тикшерүдә тотуның махсус режимын билгеләү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы, «Урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре |
| 17. | Урман фонды җирләрендә һәм Татарстан Республикасы территориясендәге башка категория-лардәге җирләрдә урнашкан торф ятмалары биләгән мәйданнарның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урманчылык» дәүләт казна учреждениеләре |
| 18. | Урман фонды җирләрендә янгын куркынычын һәм урманнарда янгын чыгуны һәр көн саен мониторинглауны | янгын куркынычы | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Ур- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | тәэмин итү | сезоны дәвамында | манчылык» дәүләт казна учреждениеләре |
| 19. | Ведомство буйсынуындагы бюджет учреждение-ләрендә янгын чыгу куркынычы булган сезонга ягулык-майлау материаллары резервын булдыруны тәэмин итү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 20. | Урман фонды, урман массивларына якын урнашкан торак пунктлар җирләрендәге территорияләрне төзекләндерүне тәэмин итү | апрель – октябрь | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, муни-ципаль берәмлекләрнең башкар-ма комитетлары (килешү буенча) |
| 21. | Урман фонды җирләрендә урнашкан, торф ятмалары биләгән мәйданнар янында, аларга транспорт керү урынын һәм су алу мөмкинлеген тәэмин итеп, су белән тәэмин итү чыганакларын (янгынга каршы сулыклар) ясау (булмаган очракта) буенча өстәмә чаралар комплексын гамәлгә ашыру | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре |
| 22 . | Урман-хуҗалык эшләре комплексын башкаруга, шул исәптән урманнарны янгыннардан саклауга, урманнарны авиация ярдәмендә саклауга һәм яклауга контракт төзү хокукына аукцион үткәрү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |